**Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Teлəнче Тамак авыл җирлеге составына керүче Хуҗи авылында гражданнар җыены нəтиҗəлəре турында**
**КАРАР**

08 ноябрь, 2022 ел № 1

«Россия Федерациясендә җирле үзидарə оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендəге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарə турында» 2004 елның 28 июлендəге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендə 2022 елның 08 ноябрендə түбəндəге мəсьəлə буенча узган гражданнар җыены нəтиҗəлəре белəн гражданнар җыены беркетмəсе тəзелде:

«2023 елда яшəү урыны буенча Teлəнче Тамак авыл җирлеге Хуҗи авылы территориясендə теркəлгəн һəр балигъ булган кешегə 500 (биш йөз ) сум күлəмендə бер тапкыр түлəү кертергə һəм I, II төркем инвалидлары һəм Бөек Ватан сугышы ветераннары, ялгыз яшəүче өлкəн яшьтəге гражданнар һəм көндезге формада укучы студентлар, күп балалы гаилəлəр өчен бер тапкыр түлəү күлəмен киметергə һəм аны əлеге категория гражданнар өчен 250 (ике йөз илле) сум күлəмендə билгелəргə, əлеге сумманы түбəндəге мəсьəлəне хəл итүгə юнəлдерергə Сез ризамы:
- Хуҗи авылында юллар ремонты

ӘЙЕ ЮК».

Гражданнар җыены нəтиҗəлəре турында беркетмə нигезендə:

Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенə гражданнар җыенында катнашучы **59** кеше кертелде, тавыш бирүдə катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны – **37** кеше.

Тавыш бирү нəтиҗəлəре буенча җыенда катнашучыларның тавышлары түбəндəгечə бүленде:

«Әйе» позициясе өчен гражданнар җыенында катнашучы **37** кеше тавыш бирде;

«Юк» позициясе өчен җыенында катнашучы 0 кеше тавыш бирде.

Бəян ителгəннəр нигезендə гражданнар җыены карар бирде:

1. Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Teлəнче Тамак авыл җирлеге Хуҗи авылында гражданнар җыенын узган, гражданнар җыены нəтиҗəлəрен гамəлдə дип танырга.

2. «2023 елда яшəү урыны буенча Teлəнче Тамак авыл җирлеге Хуҗи авылы территориясендə теркəлгəн һəр балигъ булган кешегə 500 (биш йөз ) сум күлəмендə бер тапкыр түлəү кертергə һəм I, II төркем инвалидлары һəм Бөек Ватан сугышы ветераннары, ялгыз яшəүче өлкəн яшьтəге гражданнар һəм көндезге формада укучы студентлар, күп балалы гаилəлəр өчен бер тапкыр түлəү күлəмен киметергə һəм аны əлеге категория гражданнар өчен 250 (ике йөз илле) сум күлəмендə билгелəргə, əлеге сумманы түбəндəге мəсьəлəне хəл итүгə юнəлдерергə Сез ризамы:
- Хуҗи авылында юллар ремонты

дип танырга.

3. Россия Федерациясе Кораллы Көчлəренə өлешчə мобилизациялəү буенча хəрби хезмəткə чакырылган гражданнарның, Teлəнче Тамак авыл җирлеге территориясендə теркəлгəн гаилə əгъзаларының үзара салым буенча взносларын түлəүдəн азат итəргə

4. Тукай муниципаль районы Теләнче Тамак авыл җирлеге Хуҗи авылы гражданнар җыены нәтиҗәсен авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштырып, халыкка җиткерергә.
5. Тукай муниципаль районы Теләнче Тамак авыл җирлеге Хуҗи авылы гражданнар җыены нәтиҗәсен Тукай муниципаль районының рәсми сайтында «авыл җирлекләре» бүлегендә, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Теләнче Тамак авыл җирлеге Башлыгы Р.Ш. Назметдинов